КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 21 ноябрь г.Казань № 1238

Тормыш өчен кирәкле һәм бик мөһим дару препаратлары исемлегенә кертелгән дару препаратларына бәяләрне куллануны төбәк дәүләт контролендә (күзәтчелегендә) тоту турындагы нигезләмәне раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салу өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 29 сентябрь, 921 нче карары белән расланган Бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салу өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Дару чаралары әйләнеше турында» 2010 елның 12 апрелендәге 61-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Тормыш өчен кирәкле һәм бик мөһим дару препаратлары исемлегенә кертелгән дару препаратларына бәяләрне куллануны төбәк дәүләт контролендә (күзәтчелегендә) тоту турындагы нигезләмәне расларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салу өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 29 сентябрь, 921 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 28 февраль, 186 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Бәяләрне (тариф-

ларны) дәүләт тарафыннан җайга салу өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 пунктның «ж» пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга;

13 пунктта «тормыш өчен кирәкле һәм бик мөһим дару препаратлары исемлегенә кертелгән дару препаратларын реализацияләүне,» сүзләрен төшереп калдырырга.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 21 ноябрь, 1238 нче
карары белән расланды

# Тормыш өчен кирәкле һәм бик мөһим дару препаратлары исемлегенә кертелгән дару препаратларына бәяләрне куллануны төбәк дәүләт контролендә (күзәтчелегендә) тоту турында нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Бу Нигезләмә Татарстан Республикасы территориясендә тормыш өчен кирәкле һәм бик мөһим дару препаратлары исемлегенә кертелгән дару препаратларына бәяләрне куллануны төбәк дәүләт контролендә (күзәтчелегендә) тотуны (алга таба – төбәк дәүләт контролендә (күзәтчелегендә) тоту) оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен билгели.

2. Төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруга вәкаләтле Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы – Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты (алга таба – Дәүләт комитеты).

3. Төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруга бәйле мөнәсәбәтләргә карата «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – Контроль (күзәтчелек) турында Федераль закон) нигезләмәләре кулланыла.

4. Төбәк дәүләт контроленең (күзәтчелегенең) максаты – бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салу өлкәсендәге законнар белән билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне бозу аркасында закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү рискын минимальләштерүгә бәйле, иҗтимагый әһәмиятле нәтиҗәләргә ирешү.

5. Төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) предметы – тормыш өчен кирәкле һәм бик мөһим дару препаратлары исемлегенә кертелгән дару препаратларын реализацияләгәндә дару чараларын күпләп сату оешмалары, даруханә оешмалары, фармацевтика эшчәнлегенә лицензиясе булган индивидуаль эшмәкәрләр, фармацевтика эшчәнлегенә лицензиясе булган медицина оешмалары һәм аларның авыл торак пунктларында урнашкан һәм даруханә оешмалары булмаган, аерымланган бүлекчәләре (амбулаторияләр, фельдшер һәм фельдшер-акушерлык пунктлары, гомуми табиб (гаилә) практикасы үзәкләре (бүлекләре)) тарафыннан дәрәҗәләре дару препаратларын җитештерүче билгеләгән факттагы җибәрү бәясе суммасыннан артык була алмаган һәм теркәлгән иң чик җибәрү бәяләреннән һәм Татарстан Республикасында билгеләнгән иң чик күпләп сату өстәмәләре күләмнәреннән һәм (яки) иң чик ваклап сату өстәмәләре күләмнәреннән артык булмаган шул ук эзлеклелектә күпләп сату өстәмәләре күләмнәреннән һәм (яки) иң чик ваклап сату өстәмәләре күләмнәреннән артмаган бәяләрне куллануга карата мәҗбүри таләпләрнең (алга таба – мәҗбүри таләпләр) үтәлеше.

6. Төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) объекты (алга таба – контроль (күзәтчелек) объекты) – юридик затларның һәм индивидуаль эшмәкәрләрнең (алга таба – контрольдә тотылучы затлар) бу Нигезләмәнең 5 пунктында күрсәтелгән мәҗбүри таләпләр үтәлергә тиешле эшчәнлеге, гамәлләре (гамәл кылмавы).

7. Төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар:

а) Дәүләт комитетының төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) мәсьәләләре өчен җавап бирүче рәисе (алга таба – рәис) һәм аның урынбасарлары;

б) Дәүләт комитетының төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) мәсьәләләре өчен җавап бирүче структур бүлекчәләре җитәкчеләре һәм аларның урынбасарлары;

в) Дәүләт комитетының төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) мәсьәләләре өчен җавап бирүче структур бүлекчәләренең «белгечләр» категориясе вазыйфалары төп һәм өлкән төркеменә караган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре.

8. Төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) үз вәкаләтләре чикләрендә һәм үткәрелә торган контроль (күзәтчелек) гамәлләре күләмендә гамәлгә ашырганда вазыйфаи затлар Контроль (күзәтчелек) турында Федераль законның 29 статьясындагы 2 өлешендә билгеләнгән хокуклардан файдалана.

9. Контроль (күзәтчелек) объектларын исәпкә алу контроль объектлары турындагы белешмәне, ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алына, Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары нигезендә Дәүләт комитетына бирелә торган мәгълүматны, шулай ук һәркем файдалана ала торган мәгълүматны җыю, эшкәртү, анализлау һәм исәпкә алу юлы белән гамәлгә ашырыла.

Контроль (күзәтчелек) объектлары исемлеген урнаштыруны дәүләт сере һәм закон белән саклана торган башка сер турындагы Россия Федерациясе законнары таләпләрен исәпкә алып гамәлгә ашырырга кирәк.

## II. Төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү рисклары белән идарә итү

10. Төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерүне бәяләү һәм аның рисклары белән идарә итүнең профилактика чараларын һәм контроль (күзәтчелек) чараларын сайлап алуны, аларның эчтәлеген (шул исәптән тикшерелә торган мәҗбүр таләпләр күләмен), интенсивлыгын һәм нәтиҗәләрен билгели торган системасы нигезендә гамәлгә ашырыла.

11. Тормыш өчен кирәкле һәм бик мөһим дару препаратлары исемлегенә кертелгән дару препаратларын реализацияләүне гамәлгә ашыра торган контрольдә тотылучы затларның эшчәнлеге түбән категориядәге рискка карый.

12. Планнан тыш контроль (күзәтчелек) чарасы төрен сайлау һәм үткәрү турында карар кабул иткәндә зыян (зарар) китерү рискын бәяләү максатларында мәҗбүри таләпләрне бозу рискының түбәндәге индикаторлары билгеләнә:

контрольдә тотылучы затлар эшчәнлегенә карата шикаятьләр (мөрәҗәгатьләр), дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан тормыш өчен кирәкле һәм бик мөһим дару препаратлары исемлегенә кертелгән дару препаратларына бәяләрне арттыру турында мәгълүмат керү;

мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куймау турындагы кисәтүдә билгеләнгән срок эчендә мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен тәэмин итү буенча чаралар күрү турында хәбәрнамә тапшырмау.

13. Мәҗбүри таләпләрне бозу рискы индикаторларын ачыклау Дәүләт комитеты тарафыннан, законнар таләпләрен үтәп, дөреслеген тәэмин итә торган теләсә нинди чыганаклардан, ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм оешмалардан, Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында һәм Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында тапшырырга дип каралган хисаплылыктан, контрольдә тотылучы затлар, башка гражданнар һәм оешмалар мөрәҗәгатьләреннән, массакүләм мәгълүмат чаралары хәбәрләреннән алынган, зыян (зарар) китерү рисклары дәрәҗәсе характерланган белешмәне, шулай ук мәгълүмат ресурсларындагы белешмәләрне һәм контрольдә тотылучы объектлар турында башка белешмәне анализлау һәм исәпкә алу барышында, шул исәптән профилактик чаралар, контроль (күзәтчелек) чаралары үткәрү барышында гамәлгә ашырыла.

## III. Закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү рискларын профилактикалау

14. Закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү рискларын профилактикалау программасы (алга таба – рискларны профилактикалау программасы) профилактик чаралар үткәрү елына кадәрге елның 20 декабренә кадәр Дәүләт комитеты тарафыннан раслана һәм расланган көннән биш көн эчендә Дәүләт комитетының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла.

15. Төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда түбәндәге профилактика чаралары уздырыла:

а) мәгълүмат бирү;

б) хокук куллану тәҗрибәсен гомумиләштерү;

в) кисәтүне игълан итү;

г) консультация бирү;

д) профилактик визит ясау.

16. Мәҗбүри таләпләрне үтәү мәсьәләләре буенча мәгълүмат бирү Контроль (күзәтчелек) турындагы Федераль законның 46 статьясында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

17. Хокук куллану тәҗрибәсен гомумиләштерү нәтиҗәләре бирелгән доклад хисап елыннан соң килә торган елның 1 мартыннан да соңга калмыйча әзерләнгән, 12 мартка кадәр Дәүләт комитеты рәисе боерыгы белән расланган һәм, расланган көненнән өч көненнән дә соңга калмыйча, Дәүләт комитетының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырылган булырга тиеш. Хокук куллану тәҗрибәсен гомумиләштерү нәтиҗәләре бирелгән доклад елына кимендә бер тапкыр әзерләнә.

18. Дәүләт комитетында мәҗбүри таләпләрне бозарга җыену яки мәҗбүри таләпләрне бозу билгеләре турында белешмә булганда һәм (яки) мәҗбүри таләпләрне бозу закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян салган (зарар китергән) йә

закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычын тудырган дип расланган мәгълүмат булмаганда, Дәүләт комитеты контрольдә тотылучы затка карата мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куймау турында кисәтү (алга таба – кисәтү) белдерә һәм аңа мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен тәэмин итү буенча чаралар күрүне тәкъдим итә.

19. Контрольдә тотылучы зат кисәтү алган көннән 10 көн эчендә Дәүләт комитетына кисәтүгә карата каршы килү турында гариза бирергә хокуклы.

Кисәтүгә карата каршы килү турындагы гариза кәгазь чыганакта почта аша йә электрон документ рәвешендә Дәүләт комитетының кисәтүдә күрсәтелгән электрон почта адресына йә кисәтүдә күрсәтелгән башка ысуллар белән җибәрелә.

Кисәтүгә карата каршы килү турындагы гаризада түбәндәгеләр булырга тиеш:

гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда), гариза бирүче физик затның яшәү урыны турында белешмә, гариза бирүче юридик затның урнашу урыны турында белешмә, шулай ук элемтәгә керү өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (булганда) һәм җавап җибәрелергә тиешле почта адресы;

кисәтү һәм мондый кисәтүне җибәргән вазыйфаи зат турында белешмә;

гариза бирүченең кисәтү белән килешмәвен нигезли торган дәлилләр.

Гариза бирүчеләр тапшырган документлардан кисәтүне җибәргән вазыйфаи затны билгеләү мөмкин булмаган очракларда, кисәтүгә карата каршы килү турындагы гариза, карап тикшерелмичә, карап тикшерү мөмкин булмау сәбәпләрен күрсәтеп һәм тиешле мөрәҗәгать итү тәртибен аңлатып, гариза бирүчегә кире кайтарыла.

Кисәтүгә карата каршы килү турындагы гаризалар мондый гариза алынган көннән 20 эш көне эчендә Дәүләт комитетының вазыйфаи затлары тарафыннан карап тикшерелә.

Дәүләт комитетының кисәтүгә карата каршы килү турындагы гаризаны карап тикшерү йомгаклары буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

кисәтүне үзгәртмичә калдыру;

кисәтүне гамәлдән чыгару.

20. Вазыйфаи зат контрольдә тотылучы затларга, язмача мөрәҗәгать иткәндә, язма формада йә телдән телефон аша, видеоконференция элемтәсе юлы белән яки контроль (күзәтчелек) чарасын яисә гавами чараны гамәлгә ашыру барышында вазыйфаи зат шәхси кабул иткәндә консультация бирә.

21. Вазыйфаи затлар түбәндәге мәсьәләләр буенча консультация бирүне (шул исәптән язмача) гамәлгә ашыра:

а) мәҗбүри таләпләрне куллану, аларның эчтәлеге һәм аларга үзгәреш кертү нәтиҗәләре;

б) яңа мәҗбүри таләпләрне үтәү өчен контрольдә тотылучы затлар тарафыннан гамәлгә ашырылырга тиеш булган кирәкле оештыру һәм (яисә) техник чаралар;

в) төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру үзенчәлекләре.

22. Мәҗбүри профилактик визитлар, мондый эшчәнлек башланган вакыттан алып бер елдан да соңга калмыйча, бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салу өлкәсендә җайга салына торган эшчәнлек төрен гамәлгә ашыра башлый торган контрольдә тотылучы затларга карата үткәрелә.

Мәҗбүри профилактик визитлар вазыйфаи зат тарафыннан контрольдә тотылучы затның эшчәнлек башкару урыны буенча Контроль (күзәтчелек) турында

Федераль законның 52 статьясы нигезендә үткәрелә.

23. Вазыйфаи зат контрольдә тотылучы зат эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны буенча йә видеоконференция элемтәсеннән файдаланып профилактик әңгәмә рәвешендә мәҗбүри профилактик визит ясый. Мәҗбүри профилактик визит барышында контрольдә тотылучы затка әлеге зат эшчәнлегенә яисә аның контроль (күзәтчелек) объектларына карата кулланыла торган, мәҗбүри таләпләр билгеләнгән яңа норматив хокукый актларның эчтәлеге, норматив хокукый актларга кертелгән үзгәрешләр, шулай ук аларның сроклары һәм үз көченә керү тәртибе мәсьәләләре турында мәгълүмат бирелә.

24. Мәҗбүри профилактик визит ясау дәвамылылыгы бер эш көненнән артып китә алмый.

## IV. Төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру

25. Түбән дәрәҗәдәге риск категориясенә кертелгән контроль объектларына карата план буенча контроль (күзәтчелек) чаралары үткәрелми.

26. Төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) түбәндәге контроль (күзәтчелек) чараларын үткәрү юлы белән гамәлгә ашырыла:

а) мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтү;

б) документларны тикшерү;

в) күчмә тикшерү.

27. Планнан тыш контроль (күзәтчелек) чарасын үткәрү турындагы карарда Контроль (күзәтчелек) турында Федераль законның 64 статьясындагы 1 өлешенең 1 – 14 пунктларында билгеләнгән белешмә күрсәтелә.

28. Дәүләт комитетының контроль (күзәтчелек) чараларын үткәрү турында карар кабул итүгә вәкаләтле вазыйфаи заты – Дәүләт комитеты рәисе.

29. Мәҗбүри таләпләрне бозуга бәйле дәлилләрне теркәү максаты белән бу Нигезләмәнең 26 пунктындагы «а» һәм «в» пунктчаларында күрсәтелгән контроль (күзәтчелек) чаралары вазыйфаи затлар тарафыннан фотога төшереп, аудиога һәм видеога яздырып (түбәндәгеләрне теркәү очрагыннан тыш) үткәрелергә мөмкин:

а) Россия Федерациясе законнары белән дәүләт серенә кертелгән белешмә;

б) Россия Федерациясе законнары нигезендә режимлы һәм аеруча мөһим объектларга кертелгән территорияләр, объектлар.

Дәлилләрне теркәү өчен кулланыла торган фоторәсемнәр, аудио һәм видеоязмалар, һичшиксез, мәҗбүри таләпләрнең бозылуын чагылдыра торган теркәү объектын идентификацияләргә мөмкинлек бирергә тиеш. Мәҗбүри таләпләрне бозуга бәйле дәлилләр өчен кулланыла торган фоторәсемнәр, аудио һәм видеоязмалар контроль (күзәтчелек) чарасы актына теркәлә.

Фотога төшерү, аудиога һәм видеога яздыру һәм әлеге максатлар өчен файдаланылган техник чаралар турындагы мәгълүмат контроль (күзәтчелек) чарасы нәтиҗәләре буенча актта чагылдырыла.

Фотографиягә төшерү юлы белән мәҗбүри таләпләрне бозуларны теркәү мәҗбүри таләпләрнең һәр ачыкланган бозуларын кимендә ике тапкыр фоторәсемгә төшереп гамәлгә ашырыла.

Аудиога һәм видеога яздыру контроль (күзәтчелек) чарасын үткәрү барышында өзлексез рәвештә гамәлгә ашырыла, язманың башында һәм ахырында яздыру датасы,

урыны, яздыра башлау һәм яздыруны туктату вакыты турында хәбәр ителә.

Язып кую барышында ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозу җентекләп теркәлә, һәм аның урыны һәм характеры күрсәтелә.

Фотога төшерү, аудиога һәм видеога яздыру нәтиҗәләре контроль (күзәтчелек) чарасы актының кушымтасы булып тора.

Мәҗбүри таләпләрне бозуга дәлилләрне теркәү өчен фотога төшерү, аудиога һәм видеога яздыру дәүләт һәм закон белән саклана торган башка сер турындагы Россия Федерациясе законнары таләпләрен исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

30. Контроль (күзәтчелек) турында Федераль законның 57 статьясындагы 1 өлешенең 1, 3 – 5 пунктларында билгеләнгән нигезләр булганда, Дәүләт комитеты тарафыннан түбәндәге планнан тыш контроль (күзәтчелек) чаралары үткәрелә:

а) документларны тикшерү;

б) күчмә тикшерү.

31. Мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтү, контрольдә тотылучы затлар белән хезмәттәшлек итмичә, Дәүләт комитетында булган контроль (күзәтчелек) объектлары турында мәгълүматларны, шул исәптән ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек барышында кирә торган, контрольдә тотылучы затлар тарафыннан мәҗбүри таләпләрне үтәү кысаларында бирелә торган мәгълүматларны, дәүләт һәм муниципаль мәгълүмат системаларындагы мәгълүматларны, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге мәгълүматларны, шулай ук автомат режимда эшли торган, фотога һәм киного төшерү, видеога яздыру функцияләре булган, хокук бозуларны теркәп бара торган техник чараларны файдаланып алынган мәгълүматларны җыю, анализлау юлы белән даими рәвештә үткәрелә.

32. Документларны тикшерү Дәүләт комитетының урнашу урыны буенча уздырыла.

33. Документларны тикшерү барышында түбәндәге контроль (күзәтчелек) гамәлләре башкарылырга мөмкин:

а) язма аңлатмалар алу;

б) документларны сорап алу.

34. Күчмә тикшерү контрольдә тотылучы затның (аның филиаллары, вәкилләкләре, аерымланган структур бүлекчәләре) урнашу (эшчәнлеген гамәлгә ашыру) урыны буенча үткәрелә.

Берничә федераль округ территориясендә аерымланган бүлекчәләре булган контрольдә тотылучы затка карата күчмә тикшерүләр үткәрү контроль (күзәтчелек) органының контроль (күзәтчелек) объектлары урнашу урыны буенча планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү турындагы карары нигезендә гамәлгә ашырыла.

35. Күчмә тикшерүне үткәрү срогы 10 эш көненнән артып китә алмый. Кече эшмәкәрлекнең бер субъектына карата күчмә тикшерү барышында хезмәттәшлек итүнең гомуми срогы кече предприятие өчен 50 сәгатьтән һәм микропредприятие өчен 15 сәгатьтән артып китә алмый (Контроль (күзәтчелек) турында Федераль законның 57 статьясындагы 1 өлешенең 6 пункты үткәрү өчен нигез булган һәм микропредприятие өчен 40 сәгатьтән артык дәвам итә алмаган күчмә тикшерүдән тыш).

Россия Федерациясенең берничә субъекты территориясендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган контрольдә тотылучы затка карата күчмә тикшерү үткәрү

срогы оешманың яки җитештерү объектының һәр филиалы, вәкиллеге, аерымланган структур бүлекчәсе буенча аерым, әмма иң күбе 10 эш көне эчендә билгеләнә.

36. Күчмә тикшерү барышында түбәндәге контроль (күзәтчелек) гамәлләре башкарыла:

а) карау;

б) язма аңлатмалар алу;

в) документларны сорап алу;

г) экспертиза.

37. Контрольдә тотылучы индивидуаль эшмәкәр түбәндәге очракларда Дәүләт комитетына контроль (күзәтчелек) чарасын үткәргәндә катнашу мөмкинлеге булмау турында мәгълүмат бирергә хокуклы:

эшкә сәләтен югалтуга бәйле авыру белән авырганда;

каршы тора алмаслык көчнең тәэсире аркасында барлыкка килгән каршылыклар.

Бирелгән мәгълүматны карап тикшерү нәтиҗәләре буенча контроль (күзәтчелек) чарасын үткәрү Дәүләт комитеты тарафыннан индивидуаль эшмәкәрнең мөрәҗәгать итүенә этәргән сәбәпләрне бетерүгә кирәкле срокка күчерелә.

38. Төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) оештырганда һәм гамәлгә ашырганда Дәүләт комитеты Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 19 апрелендәге 724-р номерлы боерыгы белән расланган, тикшерүләр оештырганда һәм үткәргәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында башка дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы, әлеге документлар һәм (яки) мәгълүмат белән эш итә торган оешмаларыннан соратыла һәм алына торган мәгълүмат һәм (яки) документлар исемлеге нигезендә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында (шул исәптән электрон формада) башка органнардан яисә әлеге органнарның ведомство буйсынуындагы, эш итү карамагындагы оешмаларыннан түбәндәге документларны һәм (яки) белешмәләрне ала:

фармацевтика эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензияләрнең бердәм реестрыннан белешмә;

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан белешмә;

дисквалификацияләнгән затлар реестрыннан белешмә;

Индивидуаль эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрыннан белешмә;

салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, процентлар һәм законнарны бозган өчен штрафлар түләү буенча бурычның булуы (булмавы) турында белешмә;

үткән календарь елга хезмәткәрләрнең исемлек буенча уртача саны турында белешмә;

агымдагы финанс елы өчен барлык дәрәҗәдәге бюджетларга фактта түләнгән салымнар суммасы турында белешмә;

производствода бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри авырулардан мәҗбүри социаль иминләштерү буенча ай саен бирелә торган иминият түләүләре күләме турында белешмә;

Россия Федерациясе гражданының яшәү урыны буенча теркәлү турында белешмә;

Россия Федерациясе гражданының булу урыны буенча теркәлү турында белешмә;

кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының бердәм реестрыннан белешмә;

устав (җыеп тупланган) капиталларында дәүләт милке өлеше кимендә 25 процент тәшкил итә торган оешмаларның бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгы турында аудиторлык бәяләмәләре күчермәләре;

еллык бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгын төзергә тиешле юридик затларның әлеге хисаплылыгы, шулай ук әгәр бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгы «Бухгалтерлык (финанс) хисабы турында» 2011 елның 6 декабрендәге 402-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясында каралган бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгының дәүләт мәгълүмат ресурсында булган мәҗбүри аудит үтәргә тиеш булса, аның турында аудитор бәяләмәләре.

## V. Контроль (күзәтчелек) чарасы нәтиҗәләре

39. Контроль (күзәтчелек) чарасы нәтиҗәләре Контроль (күзәтчелек) турында Федераль законның 16 бүлегендә каралган тәртиптә рәсмиләштерелә.

40. Контроль (күзәтчелек) турында Федераль законның 90 статьясындагы 2 өлешенең 1 пунктында ачыкланган бозуларны бетерү турында каралган күрсәтмә, аларны үтәүгә яраклы срокларны күрсәтеп, Дәүләт комитеты рәисе (Дәүләт комитеты рәисе урынбасары) тарафыннан Контроль (күзәтчелек) турында Федераль законның 16 бүлеге нигезендә бирелә.

## VI. Шикаять бирүнең судка кадәрге тәртибе

41. Төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру барышында Дәүләт комитетының вазыйфаи затлары гамәлләренә (гамәл кылмавына), Дәүләт комитеты тарафыннан кабул ителгән карарларга карата контрольдә тотылучы зат тарафыннан, Контроль (күзәтчелек) турында Федераль законның 9 бүлеге нигезләмәләренә таянып, судка кадәрге тәртиптә шикаять бирелергә мөмкин.

42. Дәүләт комитеты тарафыннан кабул ителгән карарларга, Дәүләт комитетының вазыйфаи затлары гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять (алга таба – шикаять) Дәүләт комитеты рәисе тарафыннан карала.

43. Шикаять аны теркәгән көннән 15 эш көне эчендә Дәүләт комитеты рәисе тарафыннан каралырга тиеш.

Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында җавап контрольдә тотылучы затка бу пунктның беренче абзацында билгеләнгән срокларда җибәрелә.

## VII. Төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) өчен төп күрсәткечләр һәм аларның максатчан күрсәткечләре, индикатив күрсәткечләр

44. Төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру эффективлыгының һәм нәтиҗәлелегенең төп күрсәткече – «Җайга салына торган бәяләр (тарифлар) өлкәсендә законнарның мәҗбүри таләпләрен үтәүче, эшчәнлекнең җайга салына торган төрләрен гамәлгә ашыручы юридик затлар һәм индивидуаль эшмәкәрләр өлеше, процент».

Төп күрсәткечнең максатчан (план буенча) зурлыгы ел саен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

45. Төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру эффективлыгының һәм нәтиҗәлелегенең индикатив күрсәткечләре:

хисап чорында план буенча үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чаралары саны;

хисап чорында планнан тыш үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чаралары саны;

хисап чорында контрольдә тотылучы объектның мәҗбүри таләпләрне бозу рискы индикаторларында расланган параметрларга туры килүен яки контрольдә тотылучы объектның мондый параметрлардан читкә китүен ачыклау нигезендә планнан тыш үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чаралары саны;

хисап чорында хезмәттәшлек итеп үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чараларының гомуми саны;

хисап чорында контроль (күзәтчелек) чараларының һәр төре буенча хезмәттәшлек итеп үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чаралары саны;

хисап чорында үзара дистанцион хезмәттәшлек итү чараларыннан файдаланып үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чаралары саны;

хисап чорында үткәрелгән мәҗбүри профилактик визитлар саны;

хисап чорында мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куймау турында белдерелгән кисәтүләр саны;

хисап чорында нәтиҗәләре буенча мәҗбүри таләпләрнең бозылуы ачыкланган контроль (күзәтчелек) чаралары саны;

хисап чорында йомгаклары буенча административ хокук бозулар турында эшләр кузгатылган контроль (күзәтчелек) чаралары саны;

хисап чорында контроль (күзәтчелек) чаралары нәтиҗәләре буенча салынган административ штрафлар суммасы;

хисап чорында контроль (күзәтчелек) чараларын үткәрүне килештерү турында прокуратура органнарына җибәрелгән гаризалар саны;

хисап чорында контроль (күзәтчелек) чараларын үткәрүне килештерү турында прокуратура органнарына җибәрелгән һәм прокуратура органнары тарафыннан килештерелмәгән гаризалар саны;

хисап чоры ахырына исәпкә алынган контрольдә тотылучы объектларның гомуми саны;

хисап чоры ахырына исәпкә алынган, риск категорияләренә кертелгән контрольдә тотылучы объектларның риск категорияләрендәге һәрберсе буенча саны;

хисап чоры ахырына исәпкә алынган контрольдә тотылучы затлар саны;

хисап чорында исәпкә алынган һәм аларга карата контроль (күзәтчелек) чаралары үткәрелгән контрольдә тотылучы затлар саны;

хисап чорында контрольдә тотылучы затлар тарафыннан судка кадәрге тәртиптә бирелгән шикаятьләрнең гомуми саны;

хисап чорында контрольдә тотучы (күзәтчелек итүче) орган тарафыннан карап тикшерү срогы бозылган шикаятьләр саны;

хисап чорында контрольдә тотылучы затлар тарафыннан судка кадәрге тәртиптә бирелгән, карап тикшерү йомгаклары буенча контрольдә тотучы органның карарын тулысынча йә өлешчә гамәлдән чыгару турында яисә контрольдә тотучы (күзәтчелек итүче) органнарның вазыйфаи затлары гамәлләрен (гамәл кылмавын) гамәлдән чыккан дип тану турында карар кабул ителгән шикаятьләр саны;

хисап чорында контрольдә тотылучы зат тарафыннан контрольдә тотучы

(күзәтчелек итүче) органның карарлары белән, вазыйфаи затларының гамәлләре (гамәл кылмавы) белән килешмәү турында суд тәртибендә җибәрелгән дәгъва гаризалары саны;

хисап чорында контрольдә тотылучы зат тарафыннан контрольдә тотучы (күзәтчелек итүче) органның карарлары белән, вазыйфаи затларының гамәлләре (гамәл кылмавы) белән килешмәү турында суд тәртибендә җибәрелгән, белдерелгән таләпләрне канәгатьләндерү турында карар кабул ителгән дәгъва гаризалары саны;

хисап чорында дәүләт контролен (күзәтчелеген) оештыруга һәм гамәлгә ашыруга карата таләпләрне тупас бозып үткәрелгән һәм нәтиҗәләре дөрес түгел дип танылган һәм (яки) гамәлдән чыгарылган контроль (күзәтчелек) чаралары саны.

_______________________